БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
8 ноябрь 2021 ел

**КАРАР**
№ 84

**Авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү вәкаләтен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар **бирде**:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарына башкару өчен авыл җирлекләре тарафыннан расланган авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү вәкаләтен тапшырырга.
2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзергә тиеш.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р. Р. Нотфуллин